**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының "Арча 6 нчы номерлы урта гомуми белем мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе**

**2 нче сыйныфының татар төркемендә уздырылган дәрес планы**

**Тема: [в] [w] авазлары һәм в хәрефе.**


Укытучы:

татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Исмәгыйлева Рәзинә Дамировна

**2 нче А сыйныфы**
**Татар теле дәресе**

**Предмет**: татар теле.
**Класс:** 2 нче сыйныф.
**Тема:** [в] [w] авазлары һәм в хәрефе.
**Максат:** язуда бер үк хәрефләр белән белдерә торган [в] [w] тартыклары турында төшенчә формалаштыру.
**Бурычлар:** [в] [w] тартыклары арасындагы охшашлык һәм аерманы ачыкларга, аларның үзенчәлеген аларга ярдәм итү;
-укучыларның иҗади фикерләү сәләте,үз-үзенә бәя бирү мөмкинлекләрен үстерүгә шартлар тудыру;
-үз фикерләрен дөрес,матур итеп әйтә белү сәләтен үстерү.
**Универсаль Уку Гамәлләре( УУГ) формалаштыру:**
Регулятив: эшләнгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү;төрле ситуациядән чыгу юлларын табу.
Танып-белү: төп билгеләрне аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру; үзеңнең белем системасында ориентлаша белү.
Коммуникатив: сорау кую һәм аларга җавап бирү,аралашу-сөйләм эшчәнлеген формалаштыра белү.
Шәхси үсеш: үз уңышларыңның (уңышсызлыкларыңның) сәбәпләре турында фикер йөртү.
**Планлаштырылган нәтиҗә:**
Предметлы:
-төп фикерне аерып әйтә белергә өйрәтү,күнегүләрне аңлап тикшерү.
Метапредметлы:
-иптәшеңә ярдәм итүдә танып-белү инициативасы,үз-үзеңне бәяли белү(Шәхескә кагылышлы УУГ);
-укытучы ярдәмендә дәреснең максатын билгели һәм формалаштыра белү(Регулятив УУГ);
-үзеңнең фикеренне телдән матур итеп әйтә белү,башкаларны ишетә һәм тыңлый белү(Коммуникатив УУГ);
-үзеңнең белем системасында ирентлаша белү(Танып-белү УУГ);
**Материаллар:** 2 нче сыйныф татар теле дәреслеге.

Дәрес план-конспекты

**I. Оештыру өлеше**

1. исәнләшү.
2. психологик уңай халәт тудыру.
3. дәрескә әзерлекләрен тикшерү.

**II. Актуальләштерү**

1. Число язу
2. Матур язу күнегүләре
3. Алда үтелгән хәрефләрне кабатлау.
4. Тартык авазларны кабатлау.
5. Өй эшен тикшерү.

**III. Ял итү**

**IV. Яңа белем һәм күнекмәләрне формалаштыру.**

1. Сүзлек диктанты
2. Проблема чишү юлы белән дәреснең темасын ачыклау.
3. Дәреснең темасын,максатын хәбәр итү.

**V. Белем һәм күнекмәләрне ныгыту**

1.Кагыйдә уку.
2. Китап буенча эшләү.
3. Мөстәкыйль эш.

**VI. Рефлексия (Йомгаклау)**

1. Дәрескә нәтиҗә ясау.
2. Өй эше бирү.
3. Билгеләр кую.
4. Саубуллашу.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру өлеше.**

1.Исәнләшү.

-Исәнмесез,укучылар. Кәефләрегез ничек? Яхшы кәефләр белән татар теле дәресебезне башлап җибәрик. Бу дәрестә сезнең белән рәхәтләнеп туган телебездә аралашырбыз дип ышанып калам.

-Хәерле көн мина,

-Хәерле көн сина,

-Хәерле көн сезгә,

-Хәерле көн,барыбызгада.

-Дәрескә барыгызда әзерме? Әзер булсагыз, дәресебезне башлап җибәрик.

**II. Актуальләштерү**

-Үткән дәрестә нәрсәләр өйрәндек?( тартык авазлар турында)

-Укучылар, искә төшерик әле, тартык авазлар ничек әйтелә?(тартык авазларны әйткәндә, авазлар тавышы һәм шау белән әйтеләләр.)

-Тартык авазлар ничә төркемгә бүләләр?(яңгырау һәм саңгырау)

-Афәрин, укучылар.

-Ә хәзер экрандагы сүзләрне укып чыгыйк. (китап,алма,дәфтәр,һәйкәл, мәктәп,укытучы,әкият,юрган)

-Тартык хәрефкә башланган сүзләрне генә аерып укып чыгыгыз. Һәр хәрефнең нинди тартык аваз икәнен әйтеп чыгабыз.

-Нәтиҗә ясап китик әле. Тартык авазлар белән ничек әйтелә.Әйтелешләре буенча нинди ике төркемгә бүленә.

-Ә бүгенге дәрестә без сезнең белән бер хәрефнең серен ачып карарбыз. Нинди хәреф икәнен дәрес вакытында белербез.

-Хәзер дәфтәрләрегезне ачабыз, числоны язабыз.. Матур язу күнегүләрен язып китәбез.

-Ә хәзер кызыл юлдан,баш хәрефтән сүзләр язабыз.

(авыл, ваза, тавык, телевизор, вагон)

-Ничек уйлыйсыз, бу сүзләрне нәрсә берләштерә икән.(В хәрефе)

-Сүзләрне ничә төркемгә бүләр идегез.(укуылар җавабы)

Модель

В

[в] [w]

-Димәк, В хәрефе татар телендә [в] [w] авазларын белдерә: [ваза]

-Татар сүзләрендә [w] авазы иреннәр ярдәмендә әйтелә: (һава,вакыт)

-Рус телендә [в] авазы ирен һәм тешләр ярдәмендә әйтелә. [диван].

-Әйдәгез истә калсын өчен сезнең белән бер уен уйнап алабыз.

-Мин сезгә сүзләр әйтәм: иреннәр ярдәмендә әйткән очракта 1 тапкыр чабып алырсыз, ә ирен һәм тешләр ярдәмендә әйткәндә 2 тапкыр куллар белән

чабырсыз.(давыл, җавап, витамин, кавын, авыл, диван, аваз, вокзал, ваза, чикләвек)

-Афәрин,укучылар.

-Укучылар,нәтиҗә ясап алыйк әле. Нәрсәләр истә калды?

-Димәк, В хәрефе татар телендә [в] һәм [w] авазларын белдерә. Татар сүзләрендә [w] авазы иреннәр ярдәмендә әйтелә.

-Рус сүзләрендә [в] авазы ирен һәм тешләр ярдәмендә әйтелә.

**III.Ял итү**

Әтәч канат кагынып
Кычкырды инде күптән.
Киерелдек, сузылдык та (Киереләләр.)
Сикереп тордык иртән. (Торып басалар.)
Урыннарны җыештырдык,
Кулларны, битне юдык
Физзарядка ясарга дип,
Тышка йөгереп чыктык. (Төрле хәрәкәтләр ясыйлар.)
Җилкә өчен, куллар өчен
Ясадык күнегүләр
һәм саф һавада йөгердек,
Күтәрелде күңелләр. (Йөгерү хәрәкәте ясыйлар.)

**IV. Яңа белем һәм күнекмәләрне формалаштыру.**

-Афәрин, укучылар. Булдырдыгыз. Алга таба киттек.

-Китапның 45нче битен ачтык һәм 62 нче күнегүне карыйбыз.

-Нияз, биремне укып кит әле.

-Димәк,безгә сүзләрнең әйтелешендәге аерманы табарга. В хәрефе кайсы сүзләрдә иреннәр ярдәмендә укыла. В хәрефе сүзнең кайсы урынында язылганын белергә кирәк.

-Димәк, укучылар, укыган буенча нәрсә әйтә алабыз? (В хәрефе сүз һәм иҗек башында языла)

-Хәзер сезнең белән группада эшләп алабыз. Сезгә мин карточкалар өләшәм. Шул карточкадагы биремнәрне эшләп китик.

-Укучылар, искә төшерик әле. Без группаларда эшләгән вакытта нинди кагыйдәләрне истә тотарга тиеш.(укучылар җавабы)

-Риназ, безгә биремне укып кит әле.

Хәрефләрне куегыз. **В** хәрефе кергән сүзләрне --кызыл , **у, ү** хәрефләре кергән сүзләрне зәңгәр карандаш белән буягыз.

| | | | |
|---|---|---|---|
| ка...ын | ...акыт | а...ыл | кә...сә |
| гә...дә | дә...ләт | кыра... | боза... |
| ба...ыр | буя... | гөрлә...ек | ...атан |
| а...лак | да...ыл | җа...ап | ...әгъдә |
| а...ыз | са...ыт | чә...кә | һа...а |
| | | | |

-Афәрин, укучылар булдырдыгыз.

-Хәзер, 63 нче күнегүне карап үтик.
-Сафия,биремне укып кит әле.
-Безгә, татар сүзләрен беренче юлга, рус теленнән татар теленә кергән сүзләрне икенче юлга күчереп язарга.
-Афәрин, укучылар. Булдырдыгыз.
**V. Белем һәм күнекмәләрне ныгыту**
-Ә хәзер [w], [в] авалары булган 5 шәр сүзләр уйлап языгыз.
-Афәрин,укучылар.
-Хәзер мин сезгә текст укып китә. Мин укыган текстан [в], [w] тартыклары кергән сүзләрне генә әйтеп барабыз.
**VI.Рефлексия (Йомгаклау)**
-Без бүген дәрестә нинди тема үттек.
-Нәрсәләр исегездә калды
-Дәрестә нәрсәләр эшләдек.
-Өй эше 64 нче күнегү.
-Дәрес бетте,чыгарга мөмкин